ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.07.2022 ел Баулы шәһәре № 124

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 249 номерлы карарына (2021 елның 30 декабренедәге 246 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 249 номерлы карарына (2021 елның 30 декабренедәге 246 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Баулы муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә (күрсәтелгән карарга 1 нче кушымта):

IV «стимуллаштыручы характердагы түләүләр» бүлегендә:

4.17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Баулы муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре

хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында мәдәният хезмәткәрләренә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча мәдәният хезмәткәрләренә, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла.»;

Баулы муниципаль районы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә (күрсәтелгән карарга 2 нче кушымта):

IV «стимуллаштыручы характердагы түләүләр» бүлегендә:

4.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. «Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча Баулы муниципаль мәдәният учреждениеләренең эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, акча булганда, бер тапкыр түләнә түләү бирелә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И. Гозәеров